КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1029

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алучы Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру чараларын күздә тота торган килешүләр турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясындагы 8 нче пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^1$ статьясындагы 8 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районының финанс органы (алга таба – финанс органы) тарафыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджетыннан (финанслар белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты субвенциясе акчасы булган) дотация алучы җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) белән төзелә торган һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру чараларын күздә тота торган килешү (алга таба – килешү) түбәндәге тәртиптә имзалана дип билгеләргә:

килешү җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджетыннан (2020 елда финанслар белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты субвенциясе акчасы булган) дотация алучы җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан имзалана һәм 2020 елның 1 февраленә кадәр финанс органына тапшырыла;

килешү, 2020 елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча, финанс органы тарафыннан имзалана.

2. Җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) 2020 елның 15 гыйнварына кадәр 2020 елда дотация алудан рәсми баш тарту кәгазен финанс органына җибәргән очракта, килешү төзелми дип билгеләргә.

3. Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла дип билгеләргә:

дотация алучы җирлекнең кушымтада бирелгән исемлек буенча йөкләмәләре;

финанс органының дотация алучы җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан тапшырыла торган, җирлекнең килешүдән барлыкка килгән йөкләмәләренә кагылышлы документларны карап тикшерү һәм бу документларга бәяләмәләр әзерләү йөкләмәләре.

4. Дотация алучы җирлекнең җирле администрация башлыгына (башкарма-боеру органы җитәкчесенә) 2021 елның 20 гыйнварына кадәр бу карарның кушымтасында каралган җирлек йөкләмәләре үтәлеше турындагы хисапны финанс органына җибәрергә.

5. Дотация алучы җирлек тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлмәве өчен җаваплылык чаралары сыйфатында түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) бу карарга теркәлгән кушымтаның 1 нче пунктындагы «в» пунктчасы, 3 нче пункты белән күздә тотылган йөкләмәләрнең үтәлмәве өчен – Татарстан Республикасы муниципаль районындагы вәкиллекле органның 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) бюджет турындагы карары белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла торган 2021 елга дотация күләмен 2021 елга күздә тотылган дотация күләменең иң күбе 1 проценты күләмендә, әмма 2020 ел өчен җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматлары буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан артмаган күләмдә киметү;

б) бу карарга теркәлгән кушымтаның 2 нче пунктындагы «а» пунктчасы белән күздә тотылган йөкләмәләрнең үтәлмәве өчен – Татарстан Республикасы муниципаль районындагы вәкиллекле органның 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) бюджет турындагы карары белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла торган 2021 елга дотация күләмен әлеге җирлек тарафыннан җирле үзидарә депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлаулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләменең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгән әлеге максат өчен чыгымнарны формалаштыру нормативлары нигезендә исәпләп чыгарылган бюджет ассигнованиеләре күләменнән арткан, әмма 2021 елга күздә тотылган дотация күләменең иң күбе 1 проценты һәм әмма 2020 ел өчен җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматлары буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең иң күбе 1 проценты күләмендә киметү.

6. Дотация алучы җирлек түбәндәге җаваплылыктан азат ителә дип билгеләргә:

бу килешүгә кул куйган җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) вәкаләтләре туктатылган һәм 2020 елда җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) (җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе)

вазыйфаларын вакытлыча башкаручы) итеп башка зат сайланган (билгеләнгән) очракта, килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен;

2020 елда җирлеккә бу карарга теркәлгән кушымтаның 1 нче пунктындагы «в» пунктчасы һәм 2 нче пунктындагы «а» пунктчасы белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүгә комачаулый торган каршы тора алмаслык вакыйгалар (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, әлеге йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен;

2019 ел белән чагыштырганда 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тормышка ашыруга субвенция күләме артуга бәйле рәвештә, әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне бүлү методикасына үзгәреш кертүгә бәйле булган мондый арту чикләрендә тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре саны арткан очракта, бу карарга теркәлгән кушымтаның 2 нче пунктындагы «в» пунктчасы белән күздә тотылган йөкләмәне үтәмәгән өчен.

7. 2020 елның 1 февраленә кадәр дотация алучы җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) әлеге вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган килешүне финанс органына тапшырмаган очракта, 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджетын формалаштырганда 2021 елга дотация күләме 2020 елга каралган дотация күләменең 10 процентына киметелә, ә бюджетында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр өлеше җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 50 процентыннан артып киткән җирлеккә карата финанс органы шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районындагы вәкиллекле органның 2020 елга (2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына) бюджет турындагы карары белән күздә тотылган дотацияләр бирүне килешү имзалана торган көнгә кадәр туктатып тора.

8. Бу карар 2020 елда җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының финанс органнары белән килешүләр төзү максатларында кулланыла дип билгеләргә.

9. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 11 ноябрь, 1029 нчы
карарына кушымта

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджетыннан (финанслар белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты субвенциясе акчасы булган) дотация алучы җирлекнең Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру чаралары күздә тотыла торган килешүгә кертелергә тиешле йөкләмәләр
исемлеге

1. Җирлекнең дотациялелеге дәрәҗәсен киметүгә һәм җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән, түбәндәгеләрне күздә тота торган чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

а) 2020 елның 1 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән билгеләнгән Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының (салымнар буенча түбәнәйтелгән ставкаларның) нәтиҗәлелеген бәяләү;

б) 2020 елның 20 ноябренә кадәр җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән салым ташламаларының (салымнар буенча түбәнәйтелгән ставкаларның) нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләрен финанс органына тапшыру;

в) 2019 елгы үтәлү дәрәҗәсе белән чагыштырганда 2020 ел өчен җирлек бюджеты үтәлеше йомгаклары буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре артуны чагыштырма шартларда тәэмин итү (процентларда);

г) җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан түбәндәгеләрне финанс органына килештерүгә җибәрү:

2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) җирлек бюджеты проектын җирлек вәкиллекле органына керткәнгә кадәр 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) әлеге бюджет проектының төп параметрларын (керемнәр төрләре буенча керемнәр; чыгымнар бүлекләре, бүлекчәләре, төрләре буенча чыгымнар; кытлык яки профицит, чыганаклар төрләре буенча җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары; 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) муниципаль бурыч алулар программасы һәм җирлекнең бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре);

2020 елга (2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына) җирлек бюджеты турындагы җирлек вәкиллекле органы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы

карарлар проектларын җирлек вәкиллекле органына керткәнгә кадәр әлеге карарлар проектларын;

Җирлекләргә бу пунктчада күрсәтелгән актлар проектларын, финанс органы тәкъдимнамәләрен исәпкә алмыйча, җирлекнең тиешле вәкиллекле органына кертмәскә.

2. Бюджет берләштерүенә юнәлдерелгән, түбәндәгеләрне күздә тота торган чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

а) бюджетында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр өлеше соңгы өч хисап финанс елының ике елы дәвамында җирле бюджетның үз керемнәре күләме 5 процентган артып киткән җирлек тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән җирле үзидарә депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлаулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары үтәлешен;

б) муниципаль учреждениеләрнең үз вакытында түләнмәгән кредит бурычлары барлыкка килүгә юл куймауны;

в) җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттырмауны, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлү нәтиҗәсендә хезмәткәрләр санын арттырырга кирәк булган очракта, җирлектәге җирле үзидарә органнарының җирлектәге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттыру турында муниципаль хокукый актлары проектларын кабул иткәнгә кадәр әлеге проектларны финанс органына килештерүгә җибәрүне тәэмин итүне;

г) Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджеты дотацияләрен керемнәр составына кертеп, җирлекләр бюджетларын Татарстан Республикасының муниципаль районы бюджетында каралган күләмнәрдән артмаган күләмнәрдә раслауны;

д) муниципаль районның берләштерелгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны киметү чаралары үткәрүне;

е) муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан норматив финанслау принциплары үтәлешен;

ж) хезмәт өчен түләү фондының хезмәткәрләр тарификациясе буенча исәпләнгән күләмнән ким булмаган күләмдә планлаштырылуын исәпкә алып, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын төзүне;

з) җирлектәге җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында 2020 елга (2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына) җирлек бюджеты турында карар, 2020 елга (2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына) җирлек бюджетына үзгәрешләр кертү турында карар урнаштыруны;

и) җирлектәге җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапларны ай саен урнаштыруны.

3. Муниципаль финанслар белән идарә итүнең сыйфатын яхшырту кысаларында түбәндәгеләрне күздә тота торган чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясы белән билгеләнгән муниципаль бурыч алуларның иң чик күләменә карата таләпләр үтәлешен;

Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп итәргә планлаштырыла торган, җирлек бюджеты турындагы карарда җирлек бюджеты кытлыгын Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирү турындагы карар кабул ителгән бюджет кредитлары суммаларыннан артыграк финанслау чыганагы сыйфатында күздә тотылган бюджет кредитлары (җирле бюджетлар счетларында акчаның калган өлешен тулыландыру өчен бюджет кредитларыннан тыш) булмауны;

һәр айның 1е хәленә карата җирлекнең финанс органына кертелә торган бурычлар кенәгәсе мәгълүматлары буенча җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмауны.

4. Бу исемлек белән күздә тотылган йөкләмәләр (бу исемлекнең 1 нче пунктындагы «в» пунктчасы, 2 нче пунктындагы «а» пунктчасы, 3 нче пункты белән күздә тотылган йөкләмәләрдән тыш) үтәлмәгән очракта, җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан җирлектәге җирле үзидарә органнарының гамәлләре (гамәл кылмавы) әлеге йөкләмәләрне бозуга китергән вазыйфаи затларына карата Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чаралары куллану буенча җирлек йөкләмәләре.

___